ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» ноябрь 2022 ел № 299

"Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган аерым бюджет оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында" 26.04.2018 елның 194 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган аерым оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында" 30.03.2018 елның 195 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары ,"Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында" 2022 елның 17 декабрендәге 1013 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, "Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган аерым оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында" 30.03.2018 елның 195 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертүгә нигезеләнеп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган аерым бюджет оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында" 26.04.2018 елның 194 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең айлык окладлары күләмнәрен исәпләү өчен, хезмәт окладының күләмен 1,061 тапкыр индексацияләргә һәм Әгерҗе

муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең хезмәт окладларын билгеләргә, аларга бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган 12688 сум күләмендә хезмәт окладын билгеләргә.»;

1.2. 3 пунктның 3 пунктчасындагы “ике процент” сүзләрен “15 процент” сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 7 пунктның 4 пунктчасындагы “ике процент” сүзләрен “15 процент” сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетында каралган акчалар чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **Р.Р. Шәрипов**